
DOI: 10.26907/2311-2042-2022-18-1-182-187

# THE OUTSTANDING ONOMATOLOGIST GUMAR FAIZOVICH SATTAROV (1932-2020)

**Gulshat Raisovna Galiullina,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
caliullina@list.ru.



**Sattarov Gumar Faizovich** (1931 – 2020) was a linguist, Doctor of Philology (1975), professor (1981), Honored Scientist of the Republic of Tatarstan (1991), Honored Scientist of the Russian Federation (2003), laureate of the State Prize of the Republic of Tatarstan in the field of science and technology (2002), Honored Professor of Kazan University. In 1994 – 1999, he was the Head of the Tatar Language Department of Kazan State University, and the author of textbooks and teaching aids for higher and secondary education. In 1983, he became a Veteran of Labor.

His scientific works are related to the areas of Turkic-Tatar onomastics, Tatar lexicology, culture of speech, ethnolinguistics, dialectology and history of the Tatar language, as well as methods of teaching the Tatar language.

**Саттаров Гомәр Фәез улы** (1931–2020) – тел галиме, филология фәннәре докторы (1975), профессор (1981), Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (1991), Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе (2003), Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты (2002), Казан университетының атказанган профессоры, 1994–1999 елларда Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасы мөдире, югары һәм гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслекләр һәм уку әсбаплары авторы. Хезмәт ветераны (1983).

Гыйльми хезмәтләре төрки-татар, диалектология һәм татар теле ономастикасы, татар лексикологиясе, сөйләм культурасы, этнолингвистика тарихы, татар телен укыту методикасы өлкәләренә карый.

**Саттаров Гумер Фаизович** (1931–2020) – языковед, доктор филологических наук (1975), профессор (1981), заслуженный деятель науки Республики Татарстан (1991), заслуженный деятель науки Российской Федерации (2003), лауреат Государственной премии Республики Татарстан в области науки и техники (2002), заслуженный профессор Казанского университета. В 1994–1999 гг. возглавлял кафедру татарского языка Казанского государственного университета, является автором учебников и учебных пособий для высшего и среднего образования. Ветеран труда (1983).

Научные труды относятся к областям тюрко-татарской ономастики, татарской лексикологии, культуры речи, этнолингвистики, диалектологии и истории татарского языка, методики преподавания татарского языка.

The well-known linguist, teacher, Turkologist-onomatologist, publicist and poet Gumar Sattarov was a versatile creator, a uniquely talented person. His numerous scientific works, profound topical journalistic articles about his native language and pathetically lyrical poems are well known to the public.

Gumar Sattarov was born on July 2, 1932 in the village of Mulla Ile, the Zelenodolsk region of Tatarstan. After leaving high school, he entered the

Faculty of the Tatar Language and Literature of Kazan State University. Upon graduating from the university with honors, he was sent to teach the Tatar language at the Tobolsk State Pedagogical Institute. After working there for several years, the young man, who dreamed of connecting his future life with science, returned to Kazan and in 1959 became a post-graduate student at the Tatar Language Department of Kazan University. Having successfully completed his postgraduate studies, the young scholar got a job at the Tatar Language Department. From 1962, G. Sattarov's life was connected with Kazan University. In 1963, he presented his Ph.D. thesis "The development of the Tatar language culture among 5–8 grade students in the context of local dialects". The outstanding scholar Mirfatykh Zakiev was his scientific supervisor.

In 1965, G. Sattarov's book "Maktapta tel kulturasy" ("Language Culture at School") was published [1]. This work determined another trend of the young scholar's future research area.

In 1967, the scholar was awarded the academic title of associate professor.

In 1975, he presented his thesis for the degree of Doctor of Philology on the topic "Anthropotoponymy of the Tatar ASSR". Prominent turkologists, Prof. A. Tenishev, Prof. M. Zakiev and Prof. R. Kuzeev highly appreciated G. Sattarov's work, noting that it was a model of research into other Turkic languages. Thus, having studied numerous archival materials, historical sources, annals, legends and having collected a file of thousands of proper names, based on the material that he had collected during his expeditions, G. Sattarov created a unique trend in scientific research, new to Tatar linguistics – anthropotoponymy.

From that time, Gumar Sattarov's main scientific activity was closely connected with the science of onomastics. Prof. Gumar Sattarov, Doctor of Philology, Honored Scientist of Tatarstan and Russia, Honored Professor of Kazan University, was the founder of the scientific trend of onomastics, which studies proper names in Tatar linguistics. In his book "Etapy razvitiya i ocherednye zadachi tatarskoi onomastiki" ["The Stages of Development and Immediate Tasks of Tatar Onomastics"] [2], published in 1970, he outlined the essence of this scientific trend, giving the details of the history of proper names studies in Tatar history and culture, research prospects and areas of work; this work served as a program for the development of Tatar onomastics. Thanks to the efforts of the scholar, the science of onomastics in Tatar linguistics has become a scientific trend that combines theoretical and practical goals. Now, the Kazan Turkic-Tatar School of Onomastics unites a large team of researchers. The materials, they have found, make a significant contribution to the study of the history, culture, ethnogenesis and ethnolinguistics of Turkic languages, in particular the Tatar language [3, p. 3].

The main areas of the scholar's research were: Turkic-Tatar onomastics, Tatar lexicology, dialectology and history of language, language culture, lexicography, ethnolinguistics and methods of teaching Tatar.

G. Sattarov founded and developed the Kazan school of Turkic-Tatar onomastics, prepared fifty candidates of philology and nine doctors of sciences, carried out extensive work in the field of Tatar linguistics and Turkic studies.

Gumar Sattarov was a scholar who made significant contributions to the study of the Turkic peoples' onomastics. Under his guidance, representatives of the Kazakhs, Uzbeks, Shors and other Turkic peoples completed their scientific works and are now effectively working in the field of Turkic onomastics.

Gumar Sattarov selflessly developed this important branch of Tatar linguistics and Turkic studies by writing numerous scientific articles and monographs, and delivering detailed reports at scientific conferences. He was the author of 26 books on topical issues of Tatar linguistics, and more than 560 scientific articles were written by him in different languages. His works are well known not only to scholars, but also to the general public. Among them are "Tatar isemnare suzlege" ("Dictionary of Tatar Names") (Kazan, 1981) [4], "Isemen matur, kemnar kuygan?" ("You Have a Beautiful Name, Who Gave It to You?") (Kazan, 1989) [5], "Atamalar donyasyna sayakhat" ("A Journey to the World of Names") (Kazan, 1992) [6], for which Gumar Sattarov got various awards.

The scholar's work "Isemen matur, kemnar kuygan?" ("You Have a Beautiful Name, Who Gave It to You?"), which is the first comprehensive research into the field of Tatar anthroponymy, studies the origin, use, naming rituals, national traditions, development trends and evolution of the system of Tatar names in historical and linguistic terms from ancient times to the end of the 20$^{th}$ century [5, pp. 12–13; 55; 155; 158–159]. The classification of anthroponymic units, proposed by G. Sattarov, has laid the basis of later scientific research.

In 1992, another monograph by the scholar "Atamalar donyasyna sayakhat" ("A Journey to the

World of Names") was published. This paper explores the local geographical terms of the Tatar people in line with the historical and linguistic analyses. The purpose of the work, as the author notes, is to analyze local geographical terms of the Tatar language and the geographical terms, derived from them, based on the material collected in scientific expeditions over many years, on books, dictionaries, maps and other sources, to present them to the fullest possible extent and to diversify our heritage [6, p. 3].

G. Sattarov calls each chapter a "journey". The work consists of four journeys. The first is a journey into the local hydrographic terminology and toponymy of the Tatar language, the second is a journey into the local orthographic terminology and toponymy of the Tatar language; the third is a journey into the world of oikonomic terms of the Tatar language and geographical terms derived from them; the fourth is a journey to study the features of the formation and genesis of local geographical terms in the Tatar language.

The outstanding linguist S. Povarisov noted that of significance is the author's study of geographical terms, related to the community of the Ural-Altaic languages, the terms related to the community of the Altai languages, Turkic-Tatar terms, the terms that are a part of the Finno-Ugric languages, the terms from the ancient Iranian language, the terms derived from the Mongolian language, the terms derived from the Arabic-Persian language and the terms derived from the Russian language and through it from the languages of Western Europe [7, p. 23].

In 1998, the scholar's dictionary of the Tatar names was published under the title "Tatar isemnare ni soyli?" ("What Do Tatar Names Mean?") [8]. This work is a collection of Tatar male and female names that have long been in use among the Tatar people. This is the fruit of the scholar's creative work, which he has accumulated over the years. This dictionary was appreciated by the general public due to its practical purpose and today it is a reference book for parents, state name registration organizations and teachers ([9], [10], [11], [12], [13]).

The fundamental work "Tatar toponymyase" ("Tatar Toponymy") (Kazan, 1998) [14] was the result of many years of research on Tatar toponymy, conducted by the scholar. In order to identify historical and linguistic patterns, characteristic of the toponymy of the Republic of Tatarstan and other territories of the Tatars' compact residence, Gumar Sattarov used the following methods of analysis: linguogenetic, comparative historical, etymological, historical and chronological, semantic field theory, structural and grammatical component analyses, internal reconstruction, descriptive-linguistic and statistical analyses [14, p. 13]. In this work, the scholar presents Tatar geographical terms as a single system, consisting of several ethnolinguistic-chronological layers of various genetic origins, used in the Tatar language. By revealing their origin, he made an in-depth etymological analysis of a large group of geographical terms that were still considered controversial.

In 2002, Prof. Gumar Sattarov, for this work, was awarded the State Prize of the Republic of Tatarstan in the field of science and technology. It proves that the centuries-old spiritual heritage of the Tatar people is a unity of history, culture and language.

To the end of his life, Gumar Sattarov devoted himself to science: in 2019, his dictionary "Tatar isemnare" ("Tatar Names") was published [15]. And this work, like all other books by the scholar, was highly appreciated by the general public and scientists.

On June 27, 1991, Professor G. Sattarov was awarded the honorary title "Honored Worker of Science of the Republic of Tatarstan" for his achievements in science and pedagogical activities. By the Decree of the President of the Republic of Tatarstan, he was awarded the "Certificate of Honor of the Republic of Tatarstan" for his successful scientific and pedagogical activities in 1994.

The Honored Scientist of the Russian Federation and the Republic of Tatarstan, Laureate of the Kul Gali International Prize, Laureate of the State Prize of the Republic of Tatarstan in the field of science and technology, Honored Professor of Kazan University Gumar Sattarov tells us the history of our country, our people and our language in linguistic terms.

**References**

1. Sattarov, G. F. (1965). *Maktapta tel kulturasy* [Language Culture at School]. 150 p. Kazan, izd-vo KGU. (In Tatar)

2. Sattarov, G. F. (1970). *Etapy Razvitiya i Ocherednye Zadachi Tatarskoi onomastiki* [Stages of Development and Immediate Tasks of Tatar Onomastics]. 87 p. Kazan, izd-vo KGU. (In Russian)

3. Galiullina, G. R. (2007). *Tatar isemnere kupne soyli* [Tatar Names Speak Volumes]. Madani zhomga, July, 13. (In Tatar)

4. Sattarov, G. F. (1981). *Tatar isemnare suzlege* [Dictionary of Tatar Names]. 255 p. Kazan, Tatar. knizh. izd-vo. (In Tatar)

5. Sattarov, G. F. (1989). *Isemen matur, kemnar kuygan?* [You Have a Beautiful Name, Who Gave It to You?]. 255 p. Kazan, Tatar. knizh. izd-vo. (In Tatar)

6. Sattarov, G. F. (1992). *Atamalar donyasyna sayakhat* [Journey to the World of Names]. 240 p. Kazan. (In Tatar)

7. Povarisov, S. (2007). *Zhir yorage serlare* [Secrets of the Earth's Heart]. 102 p. Tugan tel game – yashau yame. Kazan. (In Tatar)

8. Sattarov, G. F. (1998). *Tatar isemnare ni soyli?* [What Do Tatar Names Mean?]. 487 p. Kazan, izd-vo "Rannur". (In Tatar)

9. *Ganiev, F. A. (1993). Isem-atamalar donyasy [The* World of Names*]*. Tatarstan. No. 11, pp. 81–84. (In Tatar)

10. *Zakiev, M. Z. (1982). Prof. G.F.Sattarov turynda* [About Prof. G. F. Sattarov]. Sovet Maktabe. No. 7, pp. 22–25. (In Tatar)

11. *Yosypov, F., Garifullin, V. (1997). Zhir yozenda zhiseme bar* [*There Is an Object on the Ground*]. Miras. No. 11, pp. 131–141. (In Tatar)

12. *Kazanskaya lingvisticheskaya shkola: Kniga pervaya: Kazanskaya tyurkologicheskaya lingvisticheskaya shkola* (2008) [Kazan Linguistic School: Book One: Kazan Turkological Linguistic School]. Pp. 255–258. Compl. M. Z. Zakiev. Kazan, Tatar. knizh. izd-vo. (In Russian)

*13. Safiullina, F. S. (1982). Isemnarnen seren achuchy* [*Revealer of the Secret of Names]. Kazan Utlary. No. 7, pp. 184–185. (In Tatar)*

14. Sattarov, G. F. (1998). *Tatar tomonimiyase* [Tatar Toponymy]. 420 p. Kazan. (In Tatar)

15. Sattarov, G. F. (2019). *Tatar isemnare: anlatmaly suzlek* [Tatar Names: An Explanatory Dictionary]. 551 p. Kazan, Tatar. knizh. izd-vo. (In Tatar)

# КҮРЕНЕКЛЕ ОНОМАТОЛОГ ГОМӘР ФӘЕЗ УЛЫ САТТАРОВ (1932–2020)

**Гөлшат Рәис кызы Галиуллина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
caliullina@list.ru.

Танылган тел галиме, педагог, тюрколог-ономатолог, публицист һәм шагыйрь Гомәр Фәез улы Саттаров – күпкырлы иҗат иясе, үзенчәлекле талантлы шәхес. Аның күпсанлы фәнни хезмәтләре, туган телебез турындагы үткен актуаль публицистик язмалары, лирик пафослы шигырьләре киң җәмәгатьчелеккә яхшы таныш.

Гомәр Фәез улы Саттаров 1932 елның 2 июлендә Татарстанның Яшел Үзән районы Мулла Иле авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлап, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Университетны бик яхшы билгеләргә генә тәмамлаганнан соң, Тубыл (Тобольск) дәүләт педагогика институтына татар теле укытырга җибәрелә. Биредә берничә ел эшләгәч, киләчәктә үз язмышын фән белән бәйләргә хыялланган егет, яңадан Казанга кайтып, 1959 елда Казан университетының татар теле кафедрасы каршындагы аспирантурага укырга керә. Аспирантураны уңышлы тәмамлагач, яшь галим татар теле кафедрасына эшкә алына. 1962 елдан Г. Саттаровның язмышы Казан университеты белән бәйләнгән. Ул 1963 елны «Җирле диалект шартларында V–VIII класс укучыларының татар теле культурасын үстерү» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Аның фәнни җитәкчесе күренекле галим Мирфатыйх Зәкиев була.

1965 елда Г. Саттаровның «Мәктәптә тел культурасы» дигән китабы басылып чыга [1]. Әлеге хезмәт яшь галимнең киләчәк фәнни юнәлешенең тагын бер тармагын билгели.

1967 елда галимгә доцент гыйльми дәрәҗәсе бирелә.

1975 елда ул «Татарстан АССР антропотопонимиясе» дигән темага филология фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсенә диссертация яклый. Күренекле тюрколог галимнәр профессор Ә. Р. Тенишев, профессор М. З. Зәкиев, профессор Р. Г. Кузеев Г. Саттаровның эшенә югары бәя бирәләр, башка төрки телләр өчен дә үрнәк булырлык эш икәнен билгеләп үтәләр. Шул рәвешле, күпсанлы архив материаллары, тарихи чыганаклар, елъязмалар, риваятьләр өйрәнеп, меңләгән ялгызлык исемнәреннән гыйбарәт картотека туплап, экспедицияләрдән алып кайткан материал нигезендә Г. Саттаров татар теле белемендә әле моңа хәтле өйрәнелмәгән уникаль фәнни юнәлешне – антропотопонимияне барлыкка китерә.

Гомәр Фәез улы Саттаровның төп фәнни эшчәнлеге шул чордан башлап, ономастика фәне белән тыгыз бәйләнгән. Татар тел гыйлемендә ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган ономастика өлкәсенә нигез салучы да филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе, Казан университетының атказанган профессоры Гомәр Саттаров. Үзенең 1970 елда язылган «Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики» [2] хезмәтендә әлеге фәнни юнәлешнең асылын билгеләп, татар тарихында һәм мәдәниятендә ялгызлык исемнәрен өйрәнү тарихын тәфсилле яктыртып, аның тикшеренү перспективасын һәм өлкәләрен ачыклады һәм, нигездә, әлеге хезмәт татар ономастикасы юнәлешенең үсеш программасы вазифасын үтәде. Галимнең тырышлыгы белән ономастика фәне татар теле белемендә теоретик һәм гамәли максатларны берләштергән фәнни юнәлешкә әйләнде. Хәзер Казан төрки-татар ономастика мәктәбе зур бер төркем белгечләрне берләштерә. Алар тарафыннан табылган материаллар төрки телләрнең, аерым алганда, татар теленең тарихын, мәдәниятен, этногенезын һәм этнолингвистикасын өйрәнүгә зур өлеш кертә [3, 3 б.].

Галимнең төп фәнни-тикшеренү юнәлешләре булып, төрки-татар ономастикасы; татар лексикологиясе; диалектологиясе һәм тел тарихы; тел культурасы; лексикография; этнолингвистика; татар телен укыту методикасы тармаклары санала.

Казан төрки-татар ономастикасы мәктәбен нигезләп һәм үстереп, 50 филология фәннәре кандидаты һәм 9 фәннәр докторы әзерләп, Г. Саттаров татар тел белеменең һәм тюркологиянең әлеге тармагында киң колачлы эшчәнлек алып барды.

Гомәр Саттаров – төрки халыкларның ономастикасын өйрәнүгә дә зур өлеш керткән галим. Аның җитәкчелегендә казах, үзбәк, шор һәм башка төрки халык вәкилләре гыйльми хезмәтләр язып, бүгенге көндә төрки ономастика өлкәсендә нәтиҗәле эшлиләр.

Гомәр Фәиз улы Саттаров татар тел белеме һәм тюркологиянең шушы мөһим тармагын фидакарьләрчә тырышлык куеп үстерә, күпсанлы фәнни мәкаләләр, монографияләр яза, гыйльми конференцияләрдә тирән эчтәлекле докладлар ясый. Ул – татар тел гыйлеменең актуаль проблемаларына багышланган 26 китап һәм төрле телләрдә язылган 560тан артык гыйльми мәкалә авторы. Аның хезмәтләре фән кешеләренә генә түгел, киң җәмәгатьчелеккә дә яхшы билгеле. Шулар арасыннан «Татар исемнәре сүзлеге» (Казан, 1981) [4], «Исемең матур, кемнәр куйган?» (Казан 1989) [5], «Атамалар дөньясына сәяхәт» (Казан, 1992) [6] китаплары өчен Гомәр Фәез улы төрле дәрәҗәдәге бүләкләргә лаек булды.

Галимнең татар теле белемендә беренче тапкыр антропонимика тармагын комплекслы өйрәнүгә багышланган «Исемең матур, кемнәр куйган?» хезмәтендә татар исемлеге тарихи-лингвистик яссылыкта борынгы чорлардан алып, XX гасыр ахырынача чорлар кысасында килеп чыгышы, кулланылышы, исем кушу йолалары, милли традицияләр, хәзерге көндә татар исемнәр системасының үсеш-үзгәреш тенденцияләре, исемнәрнең структур-ясалыш үзенчәлекләре өйрәнелә [5, 12–13; 55; 155; 158–159 б.]. Антропонимик берәмлекләрне төркемләү буенча Г. Ф. Саттаров тәкъдим иткән классификация соңрак үткәрелгән фәнни тикшеренүләрнең нигезенә салынды.

1992 нче елда галимнең «Атамалар дөньясына сәяхәт» дигән чираттагы монографиясе дөнья күрде. Әлеге хезмәттә татар халкының җирле географик терминнары тарихи-лингвистик анализ җирлегендә тикшерелә. Хезмәтнең максаты, автор билгеләгәнчә, озак еллар дәвамында фәнни экспедицияләрдә, китап, сүзлекләрдән, карталардан һәм башка чыганаклардан тупланган материалга таянып, татар теленең җирле географик терминнарына һәм алардан ясалган географик атамаларга анализ ясау, аларның бай хәзинәсен мөмкин кадәр җентекле һәм төрле яклап яктырту [6, 3 б.].

Г. Ф. Саттаров һәр бүлекне «сәяхәт» дип атый. Хезмәт дүрт сәяхәттән тора. Беренчесе – татар теленең җирле гидрографик терминологиясе һәм топонимиясенә сәяхәт, икенчесе – татар теленең җирле орфографик терминологиясенә һәм топонимиясенә сәяхәт; өченчесе – татар телендәге ойконимик терминнар һәм алардан ясалган географик атамалар дөньясына сәяхәт; дүртенчесе – татар телендәге җирле географик терминнарның төзелеш-ясалыш үзенчәлекләрен һәм генезисын ачыклау өчен сәяхәт.

Күренекле тел белгече С. Поварисов билгеләгәнчә, «Авторның урал-алтай телләре гомумилегенә карый торган географик терминнарны, алтай телләре гомумилегенә карый торган терминнарны, төрки-татар терминнарын, фин-угыр телләренә кергән

терминнарны, борынгы иран теленнән кергән терминнарны, монгол теленнән алынган терминнарны, гарәп-фарсы теленнән алынган терминнарны, рус теленнән һәм аның аша Көнбатыш Европа телләреннән алынган терминнарны махсус тикшерүе мактауга аеруча лаек» [7, 23 б.].

1998 елда «Татар исемнәре ни сөйли?» дигән исем белән галимнең татар исемнәре сүзлеге дөнья күрде [8]. Әлеге хезмәт – татар халкы арасында элек-электән кулланылып килгән татар ир-ат һәм хатын-кыз исемнәренең тупланмасы. Ул – галимнең озак еллар буена җыйнап килгән иҗат җимеше. Әлеге сүзлек, гамәли максатларны күздә тотып төзелгәнлектән, киң җәмәгатьчелек тарафыннан яратып кабул ителде һәм бүгенге көндә ата-аналарның, исемнәрне теркәү буенча дәүләт оешмаларының, укытучыларның өстәл китабы булып тора ([9], [10], [11], [12], [13]).

«Татар топонимиясе» (Казан, 1998) [14] дигән фундаменталь хезмәте галимнең татар топонимиясе буенча күп еллар дәвамында эзләнүләр нәтиҗәсе булып тора. Гомәр Фәез улы Саттаров Татарстан Республикасы һәм татарлар компактлы яшәгән башка территорияләр топонимиясенә хас булган тарихи-лингвистик закончалыкларны ачыклау максатыннан, лингвогенетик, чагыштырма-тарихи, этимологик, тарихи-хронологик, семантик кыр теориясе, структур-грамматик һәм компонентлы анализ методлары ярдәмендә һәм эчке реконструкцияләү, тасвири лингвистик, статистик анализ методларын куллана [14, 13 б.]. Галим бу хезмәтендә татар телендә кулланылган күп төрле һәм төрле генетик чыгышлы берничә этнолингвистик-хронологик катлам тәшкил иткән татар географик атамаларын бербөтен система буларак тәкъдим итә. Моңарчы бәхәсле саналган шактый зур төркем хасил иткән географик атамаларга тирәнтен этимологик анализ ясап, аларның килеп чыгышы мәсьәләләрен ачыклый.

Татар халкының озак гасырлар дәвамында тупланып килгән рухи мирасы тарих, мәдәният, тел бергәлеге икәнен исбатлап биргән әлеге хезмәте өчен профессор Гомәр Саттаров 2002 елда Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендә дәүләт премиясенә лаек булды.

Гомәр Фәез улы гомеренең ахырына кадәр үз фәненә тугрылыклы булды: 2019 нчы елда аның «Татар исемнәре» [15] дигән сүзлеге басылып чыкты. Бу хезмәте дә, галимнең һәр китабы кебек үк, киң җәмәгатьчелек һәм галимнәр тарафыннан зур бәягә лаек булды.

Профессор Г. Ф. Саттаровка фәнни һәм педагогик эшчәнлектәге казанышлары өчен 1991 елның 27 июнендә «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде. Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә 1994 елда ул уңышлы фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасының Мактау грамотасы» белән бүләкләнде.

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Кол Гали исемендәге Халыкара премия лауреаты, Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендә дәүләт премиясе лауреаты, Казан университетының атказанган профессоры Гомәр Фәез улы Саттаров атамалар теле белән илебез, халкыбыз һәм телебез тарихын сөйли.

**Әдәбият**


1. *Саттаров Г. Ф.* Мәктәптә тел культурасы, Казан: Казан унив. нәшр., 1965.150 б.
2. *Саттаров Г. Ф.* Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики, Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. 87 с.
3. *Галиуллина Г. Р.* Татар исемнәре күпне сөйли // Мәдәни җомга. 2007. 13 июль.
4. *Саттаров Г. Ф.* Татар исемнәре сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 255 б.
5. *Саттаров Г.Ф.* Исемең матур, кемнәр куйган? Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 255 б.
6. *Саттаров Г. Ф.* Атамалар дөньясына сәяхәт. Казан 1992. 240 б.
7. *Поварисов С.* Җир йөрәге серләре // Туган тел гаме – яшәү яме. Казан, 2007. 102 б.
8. *Саттаров Г. Ф.* Татар исемнәре ни сөйли? Казан: «Раннур» нәшр., 1998. 487 б.
9. *Ганиев Ф. А.* Исем-атамалар дөньясы // Татарстан. 1993. № 11. 81–84 б.
10. *Зәкиев М. З.* [Проф. Г. Ф.Саттаров турында] // Совет мәктәбе. 1982. № 7. 22–25 б.
11. *Йосыпов Ф., Гарифуллин В.* Җир йөзендә җисеме бар // Мирас. 1997. № 11. 131–141 б.
12. Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркологическая лингвистическая школа/ сост. М. З. Закиев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. С.255258
13. *Сафиуллина Ф. С.* Исемнәрнең серен ачучы // Казан утлары. 1982. № 7. 184-185 б.
14. *Саттаров Г. Ф.* Татар топонимиясе, Казан, 1998. 420 б.
15. *Саттаров Г. Ф.* Татар исемнәре: аңлатмалы сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 551 б.